# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"
Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 18
статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 1 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2010, 3 август) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктының җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 18 статьяда:

а) 1 өлешнең $4^1$ пунктында "коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларны (коммуналь комплекс оешмаларының – электр һәм (яисә) җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә товар җитештерүчеләрнең һәм хезмәт күрсәтүчеләрнең товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифлардан тыш)," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $4^2$ пункт өстәргә:

"$4^2$) "Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законда каралган җылылык белән тәэмин итүне оештыру вәкаләтләре;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты / Аппарат Президента Республики Татарстан
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 21 декабре
№ 95-ТРЗ